ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 3

13.11.2019 _ д. Канаш №1

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Юлдуз авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 26 ноябрендә Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Юлдуз авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Юлдуз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Юлдуз авылында юлларга вак таш җәю:

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Юлдуз авылы, Лесная урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында үткәрергә.

4. Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Канаш авыл җирлеге Башлыгы** **Н.Н.Вальков**